**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**КАРАРЫ**

17 май 2022 ел №86

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Биеш авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 16 апрелендәге 102-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Биеш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Биеш авыл җирлегендә бюджет процессы турында» Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Биеш авыл җирлеге Советының 2019 елның 8 ноябрендәге 172 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Биеш авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 5 пунктына түбәндәге эчтәлекле 1.1 пункт өстәргә:

«1.1) Федераль казначылык органында, Татарстан Республикасы финанс органында, муниципаль берәмлекнең финанс органында, Россия Федерациясенең бюджеттан тыш дәүләт фонды белән идарә итү органында (Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениесендә яисә кредит оешмасында) ачылган шәхси счет (счет) буенча бурычлы казна учреждениесеннән акча түләттерү турында;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Биеш авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында күрсәтергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җирлек башлыгына йөкләргә.

**Җирлек башлыгы** **Р.А. Валиев**